ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.10.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1923**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләүгә керешергә.
2. Шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында ( http:zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга .

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына карата 1
нче кушымта
08.10.2020 №1923

**Шәһәр төзелешен зоналаштыру этаплары:**
**җирлек территориясе**

1. Торак зоналар.
2. Иҗтимагый-эшлекле зоналар.
3. Җитештерү һәм коммуналь зоналар.
4. Инженерлык-транспорт инфраструктурасы зонасы.
5. Авыл хуҗалыгы кулланышындагы зоналар.
6. Рекреацион билгеләнештәге зоналар.
7. Махсус билгеләнештәге зоналар.
8. Шәһәр төзелеше регламентлары кагылмый торган җирләр билгеләнми.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
08.10.2020 №1923

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе һәм вакытлары**

| № т/б | Эш исеме | Үткәрү |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск (Зөя)авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү турында хәбәр бастырып чыгару | 14.10.2020 |
| 2 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү | 09.11.2020 кадәр |
| 3 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск (Зөя)авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын комиссия тарафыннан техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына туры килү-килмәүгә тикшерү | 16.11.2020 |
| 4 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектының техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына туры килү-килмәве турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе бәяләмәсе әзерләү | 16.11.2020 |
| 5 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан «Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары үткәрү турында карар кабул итү | 23.11.2020 |
| 6 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы " Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү, ачык тыңлаулар беркетмәләре, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү | 01.12.2020 |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын иҗтимагый фикер алышулар тәмамланганнан соң, түбәндәге кушымталар белән тәкъдим итү: җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә | 01.12.2020 |
| 8. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Свияжск(Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын Зеленодольск муниципаль районы Советына җибәрү турында карар кабул итү | 21.12.2020 |